Муниципальное бюджетное общеобразовательное учреждение
«Кугарчинская средняя общеобразовательная школа»
Рыбно-Слободского муниципального района РТ

| Рассмотрено | Согласовано | Утверждаю |
|---|---|---|
| Руководитель МО | Заместитель директора по УР МБОУ «Кугарчинская СОШ» | Директор МБОУ «Кугарчинская СОШ» |
| ________ / Г.К.Иминова | ____________/Г.Ф.Агзямова | ____________/ Х.С.Ахатов |
| подпись расшифровка | подпись расшифровка | подпись расшифровка |
| Протокол № 1 | | Приказ № 58 о/д |
| от «29» августа 2025 г. | от «30» августа 2025 г. | от «30» августа 2025г. |

**РАБОЧАЯ ПРОГРАММА**

**учебного предмета «Родная (татарская) литература »**

**(Базовый уровень)**

для обучающихся 10 – 11 классов

**село Кугарчино 2025**

# 10-11 сыйныфларда «Туган (татар) телдәге әдәбияты» курсын укыту буенча методик тәкъдимнәр

Туган (татар) телдәге әдәбият. 10 сыйныф: Урта гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2023.

Туган (татар) телдәге әдәбият. 11 сыйныф: Урта гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Д.М. Абдуллина, Г.Н. Мөхәрләмова. – Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2023.

## Аңлатма язуы

10-11 сыйныфларда «Туган (татар) телдәге әдәбияты» курсы нигезенә сәнгатьнең тормыш белән бәйләнеше, форма һәм эчтәлек, традицияләр һәм яңачалык бердәмлеге һәм укучыларның тарихи-әдәби мәгълүматларны, әхлакый-этик карашларны аңлау, төп әдәби-теоретик төшенчәләрне, татар әдәбияты тарихын үзләштерү, әдәби әсәрләрне анализлау, бәяләү, аңлату осталыгын һәм күнекмәләрен формалаштыру, туган (татар) теленең иҗади чараларын үзләштерү принциплары салынган.

«Туган (татар) телдәге әдәбият» дәресләренең эчтәлегендә түбәндәге юнәлешләр аерылып тора: татар әдәбияты әдәби барышы, проблемалы-тематик блоклар, метапредмет һәм предмет нәтиҗәләренә ирешүгә юнәлдерелгән һәм төрле компетенцияләр формалаштыруны үз эченә алган әдәбият теориясе.

Бу сыйныфларда татар әдәбиятын укыту программасының эчтәлеге һәм структурасының нигезендә модульле укыту концепциясе ята, анда «Кеше – иң югары кыйммәт», «Кеше һәм милли холык», «Кеше һәм җәмгыять», «Кеше һәм тарих», «Кеше һәм гаилә кыйммәтләре», «Кеше һәм табигать» кебек проблемалы-тематик блоклар аерып бирелә. Алар әдәбиятны үзлегеннән үсештә булган эстетик система буларак кабул итүне формалаштыру мөмкинлеге бирә. Моның нигезендә тарихи-мәдәни әһәмияте булган әсәрләрнең үзара бәйләнешле293 бербөтен тәшкил итүен аңлау ята.

«Туган (татар) телдәге әдәбият» өйрәнү түбәндәге максатларга ирешүгә юнәлдерелгән:

– укучыларда уку, сүз сәнгате әсәрләрен кабул итү культурасын формалаштыру;

– укучыларның әдәбият дәресләрендә өйрәнгән әдәби текстларны анализлау һәм интерпретацияләү күнекмәләрен мөстәкыйль куллана алуларына ирешү.

Әлеге максатлар түбәндәге бурычларны хәл итүне сорый:

– туган (татар) әдәби мирасын югары кыйммәт буларак кабул итү, аның рухи һәм милли-мәдәни кыйммәт буларак ролен аңлау мөнәсәбәтен формалаштыру;

– сәнгать әсәренең текстын анализлау күнекмәсен үзләштерү (әсәрнең төп темаларын, проблемаларын аерып чыгару, жанр һәм төр, сюжет һәм композиция үзенчәлекләрен, вакыйгаларның урынын, вакытын билгеләү һәм тексттагы стилистик чараларны, сөйләм үзенчәлеген, яшертен эчтәлекне күрә белү осталыгы);

– үзлегеннән укыган әсәрләрне, аларның аерым өлешләрен, телдән һәм язма формада анализлау күнекмәләрен формалаштыру;

– укучыга үз тәҗрибәсен телдән һәм язма формада гомумиләштерергә һәм аңы аша үткәрергә кирәкле төшенчә һәм терминологик аппаратны үзләштерү;

– төрле жанрлардагы текстларны (сорауларга җаваплар, рецензияләр, аннотацияләр h.б.) үзлегеннән булдыру осталыгын формалаштыру;

– уку стратегиясен билгеләү һәм аны тормышка ашыру осталыгы;

– уку һәм тикшеренү эшчәнлегендә уку бүлмәләрен, китапханәләр, музейлар, архивларның, шул исәптән цифрлы, виртуаль ресурсларны да куллану осталыгын формалаштыру;

– уку эшчәнлегенең төрле формаларын үзләштерү (әдәбият, сәнгать турында проект һәм тикшеренү эшләре h.б.);

– үз туган телендә телдән һәм язма сөйләмне баету өчен өйрәнелгән әдәбият әсәрләрен куллану, шул нигездә сөйләм культурасын камилләштерү.

Ахыргы нәтиҗә булып укучыларның әдәбиятны сүз сәнгате буларак кабул итүләренә ирешү, аның халыкның иҗтимагый, мәдәни тормышы, тарихы белән тирәнтен бәйләнгән булуын һәм гомуми әдәби процесс белән аерылгысызлыгын аңлау тора.

## ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ

**10 класс – 34 сәгать**

| **№** | **Тема** | **Эчтәлек** | **Сәг. саны** | **Укучылар эшчәнлегенең төп төрләре** |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Кереш (1 сәгать) | Кереш дәрес. Вакытлы матбугат турында әңгәмә | 1 | Әңгәмәдә катнашу.<br>Уку өчен журнал яки газетаны мөстәкыйль сайлау.<br>Дәреслек белән танышу, аның белән эшләү алгоритмын үзләштерү |
| 2 | Кеше – иң югары кыйммәт (11 сәгать) | Кеше – иң югары кыйммәт. Шәхеснең дөньядагы урыны, язмышы мәсьәләсе | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, иҗади уку.<br>Уку әңгәмәсе: эчтәлек буенча сорауларга җаваплар бирү, укылган әсәр турында сөйләшүдә катнашу. |
| | | Күңлемдә көн һаман аяз | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | (Г. Тукайның «Шагыйрь», «Кыйтга» («Көчләремне мин...» шигырьләре) | | Әдәби әсәр тексты белән эш: әдәби әсәрнең төрен һәм жанрын билгеләү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү.<br>Әсәр героена бәя: автор сурәтләвенә нигезләнеп, телдән, геройның портретын тасвирлау.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү |
| | | Киң Идел кочагында (Г. Рәхимнең «Идел» повестенда яшәү мәгънәсе мәсьәләсе) | 1 | |
| | | Идел өстендә ялгыз көймә (Г. Рәхимнең «Идел» повестенда ялгызлык мотивы) | 1 | |
| | | Җаныңның ваклыгын сылтама заманга... (Р. Фәйзуллинның «Җан ыңның ваклыгын...» шигырендә шәхес иреге һәм фикер иреге мәсьәләсе) | 1 | |
| | | Мин – алтын төрән! (Р. Харисның «Алтын төрән» шигырендә кеше һәм вакыт мәсьәләсе куелышы) | 1 | |
| | | Юлга чыксаң, намусың юлдаш булсын (И. Юзеевның «Өчәү чыктык ерак юлга» әсәрендә тормыш фәлсәфәсе) | 1 | |
| | | Килер буын синнән ни көтә? (Зөлфәтнең «Кем әле син?», «Дүрт җыр» шигырьләре) | 1 | |
| | | Күңел ни турында җырлый? (Р. Аймәтнең «Җәйнең соңгы җыры» шигырендә лирик герой фәлсәфәсе) | 1 | |
| | | Күңел җиһанны коча (Л. Гыйбадуллинаның «Ә очасы килә...» «...Җирдән – күккә, күктән җиргә кадәр...» шигырьләре) | 1 | |
| | | «Кеше – даһи тереклекнең терәге ул» (сочинение язу) | 1 | |
| 3 | Кеше һәм гаилә кыймммәтләре (14 сәгать) | Шәхес һәм гаилә кыйммәтләре. Әдәби әсәрләрдә мәхәббәт, гаилә мөнәсәбәтләре. | 1 | Уку: әсәрне аңлап, иҗади уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укыган әсәрләрнең темасын һәм проблемаларын билгеләү, әсәрләрнең идея эчтәлеген ачыклау, текстның тел үзенчәлекләрен ачыклау, әсәрләрдәге тел-сурәтләү |
| | | Мәхәббәт сине яраткан кешене бәхетле итү ул (Г. Исхакыйның «Остазбикә» повестенда | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | гаилә бәхете мәсьәләсе) | | чараларын ачыклау һәм аларның әдәби әсәрдәге ролен бәяләү. Әдәби әсәрне интерпретацияләү. Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү |
| | | Хатын-кыз бәхете – ана булуда (Г. Исхакыйның «Остазбикә» повестенда психологизм) | 1 | |
| | | Ана күңеленә кайгы кунмасын (Ә. Еникинең «Ана һәм кыз» хикәясендә ана һәм кыз мөнәсәбәтләренең гәүдәләнеше) | 1 | |
| | | Ана күңеле балада... (Ш. Хөсәеновның «Әни килде» драмасында гаилә мөнәсәбәтләренең асылы) | 1 | |
| | | Кешенең иң зур бурычы анасы алдында (Ш. Хөсәеновның «Әни килде» драмасының проблематикасы) | 1 | |
| | | Һәр мәхәббәтнең үз тарихы (И. Юзеевның «Гашыйклар тавы» әсәрендә мәхәббәт хисенең гәүдәләнеше) | 1 | |
| | | Мәхәббәтне ара ераклыгы сыный (И. Юзеевның «Гашыйклар тавы» әсәрендә тормыш фәлсәфәсе һәм мәхәббәт идеалы) | 1 | |
| | | «Гаилә бәхетенең нигезе яратуда» (сочинение язу) | 1 | |
| | | Мәхәббәт тормышка ямь өсти (Х. Туфанның «Әйткән идең» шигырендә дуслык, мәхәббәт һәм тугрылыкның чагылышы) | 1 | |
| | | Саф хисләр үлемнән дә көчлерәк (М. Җәлилнең «Ышанма» шигырендә рухи ныклык, мәхәббәт һәм изге бурыч мәсьәләләре) | 1 | |
| | | Улың – нәселеңнең дәвамчысы (Р. Мөхәммәтшинның «Тырыйк» хикәясендә гаилә образының чагылышы) | 1 | |
| | | Гаилә – үзе бер дәүләт ул (Р. Фәхретдиновның | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | үгет-нәсыйхәтләрендә татар гаиләсе кануннары) | | |
| | | «Яхшылык эшлә дә суга сал» (Проект эше яклау) | 1 | |
| 4 | Кеше һәм милли холык (7 сәгать) | Кеше һәм милли холык. Әдәби әсәрләрдә милли холык гәүдәләнеше | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, иҗади уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укыган текстның эчтәлегенә кагылышлы сорауларга җавап бирү, әсәрнең темасын, проблемасын, идеясен ачыклау.<br>Уку-укыту әңгәмәсе: укылган әсәр эчтәлегенә нигезләнеп әңгәмәдә катнашу, үз фикереңне формалаштыру һәм аны нигезли һәм яклый алу.<br>Текстны сөйләү: иҗади сөйләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җаваплар бирү |
| | | Ир язмышы – халык язмышы (М. Гафуриның «Үзем һәм халкым» шигыре) | 1 | |
| | | Тел – милли бердәмлек символы (Р. Әхмәтҗановның «И туган тел», «Бергәләп җырлыйк» шигырьләре) | 1 | |
| | | Туган телгә олы хөрмәт саклап (Р. Миңнуллинның «Туган телемә» шигыре) | 1 | |
| | | Үткәннәрне белсәң, киләчәгең ачык булыр (Р. Зайдулланың «Карап торам Казаныма» шигыре) | 1 | |
| | | Холыкның тискәре сыйфатлары да була (Г. Исхакыйның «Җан Баевич» драмасы милли холыкның тискәре яклары) | 1 | |
| | | Миллилегеңне югалту – милләтеңне югалту ул (Г. Исхакыйның «Җан Баевич» драмасының идея- проблематикасы) | 1 | |
| 5 | Нәтиҗәләр чыгару (1 сәгать) | Үткән материалны кабатлау. Нәтиҗәләр чыгару. | 1 | Комплекслы кабатлау.<br>Гомумиләштерү, сорауларга җаваплар бирү.<br>Контроль тест биремнәрен үтәү |

**11 класс – 34 сәгать**

| № | Тема | Эчтәлек | Сәг. саны | Укучылар эшчәнлегенең төп төрләре |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Кеше һәм җәмгыять (10 сәгать) | Кеше һәм җәмгыять (Г. Тукайның «Өзелгән өмид» шигыре) | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, иҗади уку.<br>Уку әңгәмәсе: тема буенча сорауларга җаваплар, укылган текст буенча фикер алышуда катнашу, аның нигезендә үз карашыңны формалаштыру.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: |
| | | Сүз көчле ул... (С. Рәмиевның «Сүзем һәм үзем» шигырендә тормыш идеалы) | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Фәрештә һәм шайтан көрәше (Дәрдемәнднең «Куанды ил, канат какты мәләкләр... » шигырендә халык язмышы мәсьәләсе) | 1 | геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, әсәрдән тел-сурәтләү чараларын табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү.<br>Иҗади эш: сочинение язу |
| | | Мәхәббәткә богау салып булмый (К. Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» драмасында мәхәббәт хисенең көче) | 1 | |
| | | Сугыш – кешелекнең иң зур хатасы (К. Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» драмасында кеше һәм сугыш мәсьәләсе) | 1 | |
| | | Кешелек кануннарына төзәтмәләр кертелми (Һ. Такташның «Югалган матурлык» драмасында гаилә һәм мәхәббәт мәсьәләсе) | 1 | |
| | | Заман үзгәрсә дә матурлык югалмасын (Һ. Такташның «Югалган матурлык» драмасында идеология һәм чынбарлык) | 1 | |
| | | Әманәт – намус сынавы (Х. Әюповның «Әманәт» шигыре) | 1 | |
| | | Тик исән булсын, дип, Ватаным. (Р. Валиевның «Ватаным» шигыре) | 1 | |
| | | «Гаделлек белән бу җиһан тулы нур булыр» (сочинение язу) | 1 | |
| 2 | Кеше һәм тарих (13 сәгать) | Тарих комы эзләрне күмә (Дәрдемәнднең «Без» шигыре) | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, иҗади уку.<br>Уку әңгәмәсе: укыган текстның эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар, текстның эчтәлеге һәм формасы белән бәйле сораулар формалаштыру.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: әдәби әсәрдә геройларның позицияләрен аеру, укыган әсәрнең темасын, проблемасын, идея-эмоциональ эчтәлеген билгеләү, геройның хисләрен белдерә торган сурәтләү чараларын билгеләү, сәнгатьлелек чараларын тексттан табу, аларның |
| | | Шәхес тарихи җирлектән тулысынча азат түгел (Х. Туфанның «Хәят» шигыре) | 1 | |
| | | Тарихның канлы битләре дә була (Р. Галиуллин «Боссойко» хикәясе) | 1 | |
| | | Һәр гаиләнең үз тарихы... (М. Мәһдиев «Кеше китә – җыры кала» повестенда авыл тормышы) | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | Сугыш чорының үз кануннары (М. Мәһдиев «Кеше китә – җыры кала» повестенда авыл тормышына сугышның тәэсире) | 1 | мәгънәләрен аңлау һәм текстлагы әһәмиятен билгеләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү |
| | | Яшәү дәвам итә... (М. Мәһдиев «Кеше китә – җыры кала» повестенда тарихи чор һәм аның хуҗалары) | 1 | |
| | | Үткәннәрдән килгән кунак (Т. Миңнуллинның «Шәҗәрә» драмасында күтәрелгән проблемалар) | 1 | |
| | | Намусыңа тарих тузаны кунмасын (Т. Миңнуллинның «Шәҗәрә» драмасында геройлар язмышы) | 1 | |
| | | Хәзерге ул үткәннең дәвамы буларак яши (Т. Миңнуллинның «Шәҗәрә» драмасының идеясе) | 1 | |
| | | Тарих агымына каршы барып булмый (З. Хәкимнең «Гасыр моңы» драмасында тарихи вакыйгаларның геройлар язмышына ясаган борылыш) | 1 | |
| | | Иленнән аерылган – канаты каерылган (З. Хәкимнең «Гасыр моңы» драмасында шәхес каршылыгы ) | 1 | |
| | | Кеше язмышы – үзе тарих (З. Хәким «Гасыр моңы» драмасында тарихи чор һәм геройлар язмышы) | 1 | |
| | | «Кеше китә – җыры кала» (проект эше яклау) | 1 | |
| 3 | Кеше һәм табигать (10 сәгать) | Әдәби әсәрләрдә кеше һәм табигать мөнәсәбәтләрен чагылдыру | 1 | Уку: мәгънәсен аңлап, иҗади уку.<br>Әдәби әсәр тексты белән эшләү: укылган әсәр эчтәлеге буенча сорауларга җаваплар бирү, әдәби әсәрләренең язылу вакыты, аларда сурәтләнгән чор һәм әсәрдә күтәрелгән проблемаларны чагыштыру, әсәрнең төп фикерен ачыклау, вакыйгалар эзлеклелеген билгеләү, геройга бәя бирү, автор позициясен ачыклау, әсәрдән тел- |
| | | Шул туфракта язсын яшәргә (К. Булатованың «Шушы яктан, шушы туфрактан без» шигыре) | 1 | |
| | | Табигатьнең дә хәтере бар (Г. Зәйнәшева | 1 | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | | «Таулар моңы» шигыре) | | сурәтләү чараларын табу, аларның мәгънәләрен аңлау һәм тексттагы әһәмиятен билгеләү.<br>Әдәби әсәрне интерпретацияләү.<br>Әдәби-теоретик төшенчәләрне үзләштерү.<br>Үткән материалны ныгыту: гомумиләштерү, сорауларга телдән җавап бирү.<br>Иҗади эш: сочинение язу |
| | | Болын – табигатьнең гүзәл почмагы...(Ф. Бәйрәмованың «Болын» повестенда кеше күңеленең табигать белән рухи бердәмлеге) | 1 | |
| | | Табигать гарасаты – күңелдәге ташкын хисләр (Ф. Бәйрәмованың «Болын» повестенда яшәү көче биргән мәхәббәт хисе) | 1 | |
| | | Табигать бишегең сау булса ... (Ф. Бәйрәмованың «Болын» повестенда психологизм) | 1 | |
| | | Шәфкатьлелек – табигать бүләге (Н. Гыйматдинованың «Ак торна каргышы» повесте геройларына бәя) | 1 | |
| | | Табигать могҗизасы – Ак торна (Н. Гыйматдинованың «Ак торна каргышы» повестенең темасы һәм күтәрелгән проблемалар) | 1 | |
| | | Табигатьнең үче аяусыз (Н. Гыйматдинованың «Ак торна каргышы» повестенең идеясе) | 1 | |
| | | «Табигать яратуга мохтаж» (сочинение язу) | 1 | |
| 4 | Нәтиҗәләр чыгару (1 сәгать) | Үткән материалны кабатлау. Нәтиҗәләр чыгару. | 1 | Комплексны кабатлау.<br>Гомумиләштерү, сорауларга җаваплар бирү.<br>Контроль тест биремнәрен үтәү |